Чыганак: Мәгариф. – 2011. – № 12. – Б. 56-57



СИБГАТ ХӘКИМНЕҢ ТУУЫНА — 100 ЕЛ

Сибгат Хәким



1911 — 1986

# КҮҢЕЛЕМ ШАГЫЙРЬ БЕЛӘН СӨЙЛӘШӘ

**Гөлфия ГАЛИЕВА, Әтнә районы Күңгәр урта мәктәбе укытучысы**

**Максат.** Укучыларның Татарстанның халык шагыйре С.Хәким иҗаты һәм аның тормыш юлы белән кызыксыну, шагыйрь иҗатына нигезләнеп, туган якны, аның табигатен, кешеләрен, әниләрне ихтирам итү хисе тәрбияләү; эстетик зәвыкларын үстерү.

Кичә С.Хәким шигыренә язылган «Башка берни дә кирәкми» *(М.Мозаффаров көе)* җыры белән башланып китә. Җыр ахырында сәхнәгә дүрт алып баручы чыга.

**1 нче алып баручы.** Сөекле һәм талантлы якташ шагыйребез, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Россиянең М.Горький исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәкимнең тууына 100 ел тулуга багышланган кичәбезне башлыйбыз.

**2 нче алып баручы.** Сибгат Хәким гаять кешелекле, акыллы, тыйнак һәм йомшак табигатьле Шәхес була. Тыйнаклык аның холкында, табигатендә. Ләкин йомшак холыклы, тыйнак кеше милли мәсьәләләрдә нык буынлы була килә. Рәсми олуг җыелышларда өстән «русча гына сөйләгез» дип торганда да, Сибгат Хәким фикерен гел Ана телендә әйтә: «Кирәк булса, ишетерләр, кирәк булса, аңларлар, тәрҗемә итәрләр», — ди торган була.

**3 нче алып баручы.**

Алтын телле иҗат алып килеп,
Дәртле моңлы көчле халыкка,
Азмы гәүһәр өстәдең син, Сибгат ага,
Ук та алмый, туп та ватмый торган
Тукай әйткән рухи байлыкка.

**4 нче алып баручы.**

Гөрләп-дөрләп яна-яна яшәп,
Гаҗәп гүзәл иҗат юлында
Азмы байлык өстәдең син, Сибгат ага,
Халкыбызның алтын фондына.

**1 нче алып баручы.** Ерак диңгезләргә коючы зур ташкын елгалар төптән, җирнең нәкъ үзәгеннән ургып чыгучы кечкенә чишмәләрдән башлана. Чишмә ничаклы тирәннәнрәк күтәрелсә, аның суы да шул чаклы тәмлерәк, сафрак һәм салкынрак була.

**2 нче алып баручы.** Өлкән шагыйребез С.Хәким иҗаты да — чишмә кебек саф, тормышның үзе кебек үк мәңгелек шигърият чишмәсе.

*«Таң атканда» (С.Хәким шигыре, татар халык көе) җыры башкарыла.*

**3 нче алып баручы.** Талантлы шагыйребез С.Хәким 1911 елның 4 декабрендә районыбызның Күлле Киме авылында крестьян гаиләсендә туа.

**4 нче алып баручы.** Иҗат башында шагыйрьгә әнисе:

— Күңелең синең ак, улым! — дигән. Бу — ана кеше улының тормышын алдан күргән дигән сүз.

Күңелдә, әнкәй, туган як
Бербөтенгә әверелә,
Колак салам шул илаһи
Бөек көчнең әмеренә.

**1 нче алып баручы.** Крестьян улының балачагы һәм яшьлеге авыл табигатендә, киеренке хезмәт атмосферасында үтә.

**2 нче алып баручы.** Шагыйрь иҗаты тамырларында җирсү дигән хиснең каны ага. Ватанга, Туган туфракка, сагышлы авылның үзганына, югалган һәм югала барган йолаларыбызга җирсү С.Хәким иҗатының буеннан-буена сузылып бара.

**3 нче алып баручы.**

Пошкырып атлар уза юлдан,
Олау тавышы җәелә кырларга.
Яратам мин кышкы озын төндә
Юлчыларның җырын тыңларга.

**4 нче алып баручы.**

Авыруыма табиб кирәк түгел,
Йөрәгемнең беләм дәвасын,
Һәр ел саен иснәп киләм,
Авылымның чиста һавасын.

*Дүрт укучы шагыйрьнең туган авылга багышлап язган «Туган җир көе», «Туган як», «Чыпчык та чытырманым дигән», «Үрләремне менгәч» дигән шигырьләрен укый.*

*«Бер тауда ун чишмә» җыры (С.Хәким шигыре, Ә.Фәттах көе) башкарыла.*

**1 нче алып баручы.**

Бу кырлар, бу үзәннәрдә минем
Үзем генә белгән җырлар бар...
Кайтам, кайтам туган якларыма,
Ашкындырып көткән юллар бар.

**2 нче алып баручы.** Шагыйрь С.Хәкимнең патриотик хисләре авыл табигате һәм аның кешеләре белән бәйле. Һәркайда һәм һәрчак үзен шул кешеләрдән аерылгысыз итеп сизә.

*Шагыйрьнең авылдашларына багышланган «Сары капкалы йорт», «Почта егете», «Җырлары рымда телим», «Рәшидә сукмагы», «Гыйльметдин рамнары» дигән шигырьләре укыла. Әлеге шигырьләр «Кайда да йөрәктә» (М. Мозаффаров музыкасы) көе фонында бара.*

**3 нче алып баручы.** С. Хәкимнең авыл темасына язылган шигырьләрен укыганда, туган якларын сагынып кайткан киек казлар тавышын ишетәсең, кинәт яуган яңгырдан соң һавага күтәрелгән дымлы җир исен тоясың. Хисләре ирләрнекедәй тыйнак, аналарныкыдай нәфис аның.

*«Син чыгасың, әнкәй, коега» (С.Хәким шигыре, С.Садыйкова көе) дигән җыр яңгырый.*

**4 нче алып баручы.** С.Хәким Күлле Кимедә беренче мәртәбә Тукай әкиятләрен тыңлаган, шигырьләрен ишеткән. Шуңа күрә бөек шагыйребез Г.Тукайга мәхәббәте чиксез зур аның.

*«Тукай маршы» ( З.Яруллин көе) уйнала.*

**1 нче алып баручы.** Тукай С.Хәкимне халык рухына алып керә, үз җиренә, үз теленә бик нык бәйли.

**2 нче алып баручы.** «Тукай тирәнгә кергән, уртага, диңгезнең актарылган төшенә кергән, диңгез белән бергә кайнаган, диңгез үзен яр читендәге ташларга китереп бәрер дип куркып калмаган», — ди шагыйрь С.Хәким.

**3 нче алып баручы.** С.Хәким әдәбиятка Тукай җигеп биргән «Пар ат»та килеп керә. Шагыйрьнең Казан артына, Кырлай якларына, Тукайга карата мәхәббәт хисләре беренче мәртәбә «Пар ат» поэмасында гәүдәләнә.

Язлар килгәч, Кырлай урманында
Көязләнеп үсә яшь каен.
Яшел ботакларын түбән иеп,
Ул сагына җырчы Тукаен.

**4 нче алып баручы.**

Тукай теле, аның «Туган тел»е —
Әйтерсең, бер изге догалык.
Шәмаилләр итеп элгән халык;
Әй, бу халык, бөек халык.

*Укучылар барысы бергә Г.Тукай сүзләренә язылган «Туган тел» җырын башкара.*

**1 нче алып баручы.** Тукай һәм Сибгат Хәким. Бер яктан — халык моңын үзәгендә тулаган Тукай, икенче якта — ул күрергә теләгән яңа авыллар. Бер якта — атсыз тилмергән крестьян, икенче якта — хөкүмәт. Әнә шундый итеп күтәрелде С.Хәким поэзиясе.

*Дүрт укучы шагыйрьнең «Тукай һәйкәле янында», «Шүрәле», «Гел кояшка карый тәрәзәләрең», «Тукай — йолдыз» дигән шигырьләрен яттан укый.*

**2 нче алып баручы.** Немец-фашистлары безнең илгә ябырылгач, яшь шагыйрь кулына мылтык ала, өстенә соры шинель кия, данлы совет гаскәрләре сафында укчы взводының командиры булып, Украинаны, Молдавияне фашизмнан азат итешә.

**3 нче алып баручы.** Ржев, Курск дугасында күрсәткән батырлыклары өчен ул Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Шагыйрь С.Хәким Тукайга биргән антын әнә шулай солдат Хәким булып та үти.

*Дүрт укучы С.Хәкимнең «Уналты йорт безнең тыкрыкта», «Усал диләр мине», «Нигә мине әзәрлекли язмыш?» «Дүрт яран» дигән шигырьләрен яттан укый.*

*«Әй, язмыш, язмыш» (С.Хәким шигыре, С.Садыйкова көе) җыры башкарыла.*

**4 нче алып баручы.** Шагыйрь С.Хәким Тукай һәм туган як, сугыш һәм халыклар язмышы турында язган шигырьләре өчен 1960 елда ук республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнә.

**1 нче алып баручы.** С.Хәким иҗаты — интернациональ бизәкле бай иҗат. Аның туган авылы Күлле Киме Мари Иле республикасы белән чиктәш. Үзән буйлап ага торган елганың бер ягында — мари, икенче ягында татар авыллары тезелгән. Алар, гасырлар буе бер-берсенә ярдәм кулы сузып, яхшы күршеләр булып, дус-тату яши.

*Шагыйрьнең «Кадерле почмак», «Мари кызы Улина», «Тарлюк» дигән шигырьләре яттан укыла.*

**2 нче алып баручы.** С.Хәкимнең иҗаты, тормышы үзе кебек үк мәңгелек, чөнки аның иҗаты — халык күңеле көзгесе. Шигырьләренең һәр юлы халык фикере, хисе, моңы белән сугарылган. Чөнки ул үзе халыкның әдәби, мәдәни мирасын, көрәш тарихын, өмет-хыялларын бик яхшы белә. Шуңа да аны: «Олуг шагыйребез, халык шагыйре», — дип атыйбыз.

*«Өянкеләр» ( С.Хәким шигыре, Р.Яхин көе) дигән җыр башкарыла.*

**3 нче алып баручы.**

Йөрәк үзе нәни генә дә ул,
Ә шулай да көчле, күрәсең,
Антей күтәрмәсне күтәрә бит,
Синең, Хәким, илчән йөрәгең,
лирик йөрәгең.

**4 нче алып баручы.**

Безнең инешнең су башы
Кушлавыч тирәсеннән,
Олы юлның башлануы
Саф Тукай чишмәсеннән.

**1 нче алып баручы.**

Ил чакырган чакта онытмадың
Дусларыңны юлга дәшәргә.
Алгы сафта барган җырың белән
Яшәргә дә Сезгә, яшәргә.

**2 нче алып баручы.**

Кемдер җырлый Фазыл чишмәсен,
Шул көйдәге чулпы чыңнарын да
Кабат-кабат килә ишетәсе.
Шул моң кебек чиртеп күңелләрне
Һаман аксын Сибгат чишмәсе.

**3 нче алып баручы.**

Чын шагыйрьнең һәр нияте изге,
Һәр гамәле аның саваплы —
Яу кырында Ватан солдаты син,
Шигърияттә — Тукай солдаты.

Гел үрләргә таба атлыйсың син,
Син сайлаган юллар и якты!
Яу кырында Ватан солдаты син,
Шигърияттә — Тукай солдаты!

**4 нче алып баручы.** С.Хәкимнең шигырьләрен укыган саен укыйсы, ихтыяри кереп сагышлы моңга чолганасы килә. Бу моңнар, бу хисләр беркайчан да искерәчәк түгел. Шунда түгелме шагыйрьнең олылыгы, шунда түгелме шагыйрь рухының үлемсезлеге!